СОВЕТ ЗАИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

30.04.2020 г. Заинск №520

**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Якты Күл авыл җирлегенең генераль планын раслау турында**

Территориянең тотрыклы үсешен, инженерлык, транспорт һәм социаль инфраструктураны үстерүне, гражданнар һәм аларның берләшмәләре мәнфәгатьләрен исәпкә алуны тәэмин итү максатларында, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 9, 24, 25 статьялары, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14, 15 статьялары, "Татарстан Республикасында шәһәр төзелеше эшчәнлеге турында" 2010 елның 25 декабрендәге 98-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 10 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Уставына таянып, ачык тыңлаулар үткәрү нәтиҗәләре турында бәяләмәне исәпкә алып, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Советы

## КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Якты Күл авыл җирлегенең генераль планын расларга (кушымта).
2. Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Советының оештыру бүлегенә әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.
3. Карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

**Совет Рәисе** **Р.Г. Кәримов**